| | | |
|---|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>РЫБНО-СЛОБОДСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАЛЫК БИСТӘСЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24.09.2020 пгт. Рыбная Слобода № 188пи

2020 елның икенче яртыеллыгына гражданнарның керемнең һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чик күрсәткечләрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә, «Татарстан Республикасы Дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күләмнәрен билгеләү методикасы белән , күрсәтелгән законга кушымтада бәян ителгәннәрдән чыгып, Россия Төзелеш Министрлыгының «2020 елның икенче яртыеллыгына Россия Федерациясе буенча торак урыны гомуми мәйданының бер квадрат метрының нормативы һәм 2020 елның III кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урыны гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе күрсәткечләре турында» 2020 елның 29 июнендәге, 351/пр боерыгы белән, шулай ук Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 46 статьясына таянып, КАРАР БИРӘМ:

1. 2020 елның икенче яртыеллыгында гражданнарны аз керемле дип тану турында карар кабул итү өчен, кушымта нигезендә, чик күрсәткечләр билгеләргә.

1.1. Гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакы ставкасы:

ялгыз яшәүче граждан өчен - 1 749 792 сум;
ике кешелек гаилә өчен - 2 227 008 сум;
өч кешелек гаилә өчен - 2 863 296 сум;
дүрт кешелек гаилә өчен - 3 817 728 сум;
биш кешелек гаилә өчен - 4 772 160 сум;
алты кешелек гаилә өчен - 5 726 592 сум;
җиде кешелек гаилә өчен - 6 681 024 сум.

1.2. гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең максималь күләме:

- ялгыз яшәүче граждан өчен - 19 927 сум 44 тиен;
- ике кешелек гаилә өчен - 9 963 сум 72 тиен;
- өч кешедән һәм аннан да күбрәк кеше өчен - 6 642 сум 48 тиен;

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлегенә социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә куелганда, әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктчаларында күрсәтелгән чик күрсәткечләрдән файдаланырга,

3.Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең веб-адрес буенча: http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталы» веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru/ Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары Д.Н. Ризаевка йөкләргә.

Җитәкче Р.Л. Исланов

Балык Бистәсе муниципаль районы
Башкарма комитетының 2020 елның
24 сентябрендәге 188пи номерлы
карарына кушымта

**2020 елның икенче яртыеллыгына һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданнарга туры килә торган керемнең чик күрсәткечләрен һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакын билгеләү МЕТОДИКАСЫ**

1. Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирү нормасы буенча торак урыннар алуның базар хакының исәп-хисап күрсәткече (алга таба - хисап күрсәткече) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

СЖ = НП x РС РЦ, анда:

СЖ - базар бәясенең исәп-хисап күрсәткече яисә мөлкәт бәясенең кимчелеге;

НП - гаиләнең бер әгъзасына торак урын бирү нормасы;

РС - гаилә әгъзалары саны;

РЦ - торак урынның торак мәйданының 1 кв.м уртача исәп-хисап бәясе, ул Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тарафыннан раслана (2020 елның 3 кварталына - 53 024 сум);

а) ялгыз яшәүче граждан өчен:

СЖ = 53024 x 33 = 1 749 792;

б) ике кешелек гаиләгә:

СЖ = 53024 x 42 = 2 227 008;

в) өч кешелек гаиләгә:

СЖ = 53024 x 18 x 3 = 2 863 296;

г) дүрт кешелек гаиләгә:

СЖ = 53024 x 18 x 4 = 3 817 728;

д) биш кешелек гаиләгә:

СЖ = 53024 x 18 x 5 = 4 772 160;

ж) алты кешелек гаиләгә:

СЖ = 53024 x 18 x 6 = 5 726 592;

з) җиде кешелек гаиләгә:

СЖ = 53024 x 18 x 7 = 6 681 024.

2. Граждан гаиләсенең һәр әгъзасына туры килә торган айлык уртача җыелма керем күләме күрсәткече түбәндәгечә билгеләнә:

ПД = 0,7 x x x ПС / (1 - [1 + ПС) - КП) / (0,3 x РС), кайда:

СЖ - исәп күрсәткече;

ПС - кредит буенча бер ай эчендә процент ставкасы (7/12);

КП - кредитның бөтен срогында кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (айлар саны);

РС - гаилә әгъзалары саны;

0,7 - кредит суммасының һәм фатир бәясенең нисбәте;

0,3 - кредит буенча түләүнең гаилә айлык җыелма кереме белән нисбәте;
а) ялгыз яшәүче граждан өчен:
ПД = (0,7 х 1 749 792 х 7/12) / (1 - [1 + 0,58) - 144) / (0,3 х1) = 16 606,20;

б) ике кешелек гаиләгә:
ПД = (0,7 х 2 227 008 х 7/12) / (1 - [1 + 0,58) - 144) / (0,3 х 2) = 8 303,10;

в) өч кешелек һәм аннан да күбрәк гаиләгә:
ПД = (0,7 х 2 863 296 х 7/12) / (1 - [1 + 0,58) - 144) / (0,3 х 3) = 5 535,40;